**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Центральная, д. 3, с. Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯҢА КЫРЛАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Үзәк урамы, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 23 » гыйнвар 2023ел** **№ 1**

**"Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары схемасын һәм реестрын раслау турында" Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 18 апрелендәге 47 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 2018 елның 25 декабрендәге 89-ФЗ номерлы Федераль законның 13.4 статьясы (25.12.2018 ред.), «Каты коммуналь калдыклар җыю урыннарын (мәйданнарын) урнаштыру һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турындагы» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 августындагы 1039 номерлы карары нигезендә Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру реестрын һәм схемасын раслау турында» Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 18 апрелендәге 47 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары реестрын 1 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

1.2.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыкларын урнаштыру урыннары схемасын 2 нче кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм гражданнар күпләп җыела торган урыннарда Яңа Кырлай, Үзәк урам, 3 йорт, Өчиле авылы, Тукай урамы, 73 йорт адреслары буенча мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Яңа Кырлай авыл
җирлеге башлыгы Г.Г. Сәфәров

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОГРН 1121690009275
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОКЫРЛАЙСКОГО СП
ИНН/КПП 1609012734/160901001

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге
башкарма комитетының
“23” гыйнвар 2023 ел, №1
карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Яңа Кырлай авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру урыннары реестры**

| N | ККК җыю урыннары (мәйданчыклары) турында мәгълүмат (адрес һәм (яисә) географик координаталар турында белешмәләр) | ККК туплау урыннарының (мәйданчыкларының) техник характеристикалары турында мәгълүмат (файдаланыла торган өслек, мәйдан, урнаштырылган һәм урнаштыруга планлаштырыла торган контейнерлар һәм бункерлар саны турындагы белешмәләр, аларның күләме күрсәтелә) | ККК туплау урыннары (мәйданчыклары) милекчеләре турында мәгълүмат (Юридик затлар өчен: тулы исеме һәм ОГРН, адресы,ЕГРЮЛда язмалар ; Шәхси эшмәкәрләр өчен: Ф.И.А.И., ОГРН, ЕГРИПта язмалар, яшәү урыны буенча теркәлү адресы; Физик затлар өчен: Ф.И.А.И., паспортның яисә шәхесне таныклаучы башка документның сериясе, номеры һәм бирү датасы, яшәү урыны | ККК туплау урыннарында (мәйданчыкларда) төзелә торган каты коммуналь калдыклар барлыкка килү чыганаклары турында мәгълүмат (физик һәм юридик затларның эшчәнлекләрен гамәлгә ашырганда тиешле урыннарда (мәйданчыкларда) КККК туплау урыннары барлыкка килә торган бер яисә берничә капиталь төзелеш объекты, җирлек территориясе (территориясенең бер өлеше) турында белешмәләр) |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | буенча теркәлү адресы, контакт мәгълүматлары) | |
| 1 | Яңа Кырлай авылы, Үзәк ур., 3 й. | 1 куб метрлы 2 контейнер | Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге | ЛПХ тереклек эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган ККК |
| 2 | Яңа Кырлай авылы, Тукай ур., 11 й. | 1 куб метрлы 2 контейнер | Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге | ЛПХ тереклек эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган ККК |
| 3 | Яңа Иябаш авылы, Үзәк ур., 22А й. | 1 куб метрлы 2 контейнер | Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге | ЛПХ тереклек эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган ККК |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Яңа Кырлай авыл җирлеге
башкарма комитетының
“23” гыйнвар 2023 ел, №1
карарына
2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Яңа Кырлай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнер мәйданчыклары урнаштыру урыннары схемасы**

Яңа Кырлай авылы,Үзәк ур., 3 й.



Яңа Кырлай авылы, Тукай ур., 11 й.



Яңа Иябаш авылы, Үзәк ур., 22А й.

